Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Полянка авыл җирлеге башкарма комитеты

Карар

31.01.2020 ел. 2 номерлы

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Полянка авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр
күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә
торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Полянка авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6124,86 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2.Әлеге карар 2020 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында» 13.03.2019 ел. 3-1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Полянка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Полянка авыл җирлеге битендә Спас муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ www.spassriy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) законда билгеләнгән вакытта бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

**Полянка авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе** **Г.Г. Сибгатуллина**

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ПОЛЯНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ИНН 1637005626 ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПОЛЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 31 гыйнварындагы 2 номерлы карарына 1 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлегендә вафат булган ир яисә хатынны, якын туганнарын, башка туганнарын яисә законлы вәкилләрен җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтләр атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Мәет күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2166,30 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратта ташу | 928,48 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3030,08 |
| **Барлыгы:** | 6124,86 |

Татарстан Республикасы Спас муниципаль
районының Ямбакты авыл җирлеге башкарма
комитетының 2020 елның 31 гыйнварындагы
2 номерлы карарына 2 нче кушымта

2020 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Полянка авыл җирлегендә вафат булмаган ир яисә хатынны, якын туганнарын, башка туганнарын яисә законлы вәкилләрен җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе

| **Хезмәтләр атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда)** |
|---|---|
| 1. Оформление документов, необходимых для погребения | 0 |
| 2. Тән киму | 348,18 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1818,12 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратта ташу | 928,48 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күму) | 3030,08 |
| **Барлыгы:** | **6124,86** |